ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЕЛАБУЖСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

05.08.2021 № 1127

Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Алабуга шәһәрендә Бөтенроссия Спас ярминкәсе Нигезләмәсен раслау турында» 2018 елның 17 июлендәге 969 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Халык сәнгать һөнәрләре турында» 1999 елның 6 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә сәүдә эшчәнлеген дәүләти җайга салу нигезләре турында» 2009 елның 28 декабрендәге 381-ФЗ номерлы Федераль закон, «Халык сәнгать һөнәрләре һәм кәсепләре турында» 2005 елның 12 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Алабуга шәһәрендә Бөтенроссия Спас ярминкәсе турында Нигезләмәне бирелгән яңа редакциядә бәян итеп, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Алабуга шәһәрендә Бөтенроссия Спас ярминкәсе Нигезләмәсен раслау турында» 2018 елның 17 июлендәге 969 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 5 бүлектә 5.3. пунктын түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:

кулланучыларның хокукларын яклау өлкәсендә, янгын куркынычсызлыгын һәм террорчылыкка каршы тору өлкәсендә, халыкның санитар-эпидемиологик иминлеген тәэмин итү өлкәсендә, шулай ук яңа коронавирус йогышлы авыруы (COVID-19) таралуны булдырмауда Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында билгеләнгән таләпләрнең үтәлешен тәэмин итә.

2. Әлеге карар рәсми рәвештә бастырып чыгарылырга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче Л.Ф. Нургаянов